**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЗУР КҮККҮЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2020 ел, 8 апрель №184

**Зур Күккүз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Зур Күккүз авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Күккүз авыл җирлеге Советы **к а р а р и т т е**:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Күккүз авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендәге «Зур Күккүз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» 18 номерлы карарының «Зур Күккүз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» дигән 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктының бишенче абзацында «биш» сүзен «дүрт» сүзенә алмаштырырга.;

2) 3.2 пунктының җиденче абзацын төшереп калдырырга;

3) 3.3 пунктының «муниципаль хезмәт вазыйфалары» сүзләреннән соң «әйдәп баручы,» сүзен өстәргә.

2. 2020 елның 1 октябренә кадәр Зур Күккүз авыл җирлегенең Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) вазыйфасын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре куела дип билгеләргә:

һөнәри белем дәрәҗәсенә-урта һөнәри белем булу;

муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына-кимендә ике ел яки кимендә өч ел.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зур Күккүз авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Зур Күккүз авыл җирлеге Башлыгы**
**Зур Күккүз авыл җирлеге Советы Рәисе Р.Ф. Низамова**